РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЗНАКАЕВО
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул. Ленина, д.14, г. Азнакаево, 423330

Ленин урамы, 14 йорт, Азнакай шәһәре, 423330

Тел./факс(885592)7-15-50,7-00-37; E-mail:aznakay@tatar.ru, adm-aznakay@mail.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.11.2023 ел. № 57

Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 26 февралендәге 05 номерлы «Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында (05.08.2019 №26, 11.11.2019 №36, 24.04.2020 №14, 14.09.2020 №24, 01.12.2020 №28, 03.02.2021 №05, 07.06.2021 №16, 28.07.2021 №23, 21.09.2021 №29, 15.12.2021 №38, 26.09.2022 №30 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 20 июнендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 26 февралендәге 05 номерлы «Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында (05.08.2019 №26, 11.11.2019 №36, 24.04.2020 №14, 14.09.2020 №24, 01.12.2020 №28, 03.02.2021 №05, 07.06.2021 №16, 28.07.2021 №23, 21.09.2021 №29, 15.12.2021 №38, 26.09.2022 №30 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең Башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү, раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары” сүзләрен “республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү, раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясында билгеләнгән вәкаләтләр нигезендә автомобиль юллары буйлап авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 9 нчы кушымтасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның 1.2 пункты 01.03.2024 елдан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru//.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Э.Ә. Габдрахманов